күп профильле
181 нче мәктәп

# Күкнең җиденче катында

5нче чыгарылыш
31 нче гыйнвар

БУ САНДА:

Ленинград блокадасы 1
Мәктәп яңалыклары 2-3
Тыюлык көне 4

## Ленинград блокадасы





**Сугышның 79 нчы көнендә ягъни 1941 елның 8 сентябрендә, немец-фашистлары, Ленинград шәһәрен чолгап алып, аның илебез белән элемтәсен өзгән.**
**Шәһәр өчен авыр көннәр башланган, ләкин завод-фабрикалар эшләвен дәвам иттергән. 12 сентябрь мәгълүматлары буенча, шәһәрдә икмәк, ярма һәм ит 30-35 көнгә, май-45. шикәр 60 көнгә генә җитәрлек, ә ташкүмер, бик саклап тотканда да, ноябрьгә, сыек ягулык сентябрь ахырларына кадәр генә кулланырлык калагн була. Ләкин алда - 29 ай, 900 көн…**
**Сугышка кадәр Лениградта 3 млн.421 мең кеше яшәгән. Блокада елларында шуның 1,5 миллионы үтерелгән.**
**900 көн авырлыктан соң Ленинград блокадасы өзелә. Шушы Ленинград блокадасын өзүдә катнашкан сугышчыларга Ленинградта һәйкәл куела. За оборону Ленинграда медале тапшырыла.**

## Динар Бәдретдинов концерты

30 апрель көнне Динар Бәдретдинов концерт уздырды. Концерт бик җанлы һәм күңелле узды.

Укучылар баянчыга кушылып җырладылар, биеделәр, рәхәтләнеп күңел ачтылар



## Башлангыч сыйныфлар декадасы

Башлангыч сыйныфлар декадасы кысаларында 1и, 1з, 2д, 3з, 4а сыйныфларда ачык дәресләр һәм чаралар узды, укучылар фәннәр буенча яхшы белемнәрен, төрле ситуацияләрдә куллана белүләрен, үзара ярдәмләшүне, авыр мәсьәләләрне хәл итүне күрсәттеләр.

## «Уңыш белән әңгәмә»

«Уңыш белән әңгәмә» мәктәп проектында методолог, бизнес-психолог, балалар һәм өлкәннәр өчен остаз Яна Вознюк кунакта булды. Ул безгә уңышның сере, лидерның нинди сыйфатларга ия булырга тиешлеге турында сөйләде. Кунак фикеренчә, мәктәпкә бару - бик кызыклы шөгыль. Мәктәп - тормышның үсеш ноктасы, кеше тәҗрибә туплаган урын.



23-27 гыйнвар көннәрендә 10 нчы сыйныф укучылары «Патриот» республика спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә чакырылуга кадәрге яшьләрне әзерләү үзәге базасында «Авангард» хәрби хезмәт нигезләре буенча «тормыш иминлеге нигезләре»предметы кысаларында республика җыеннарында катнаштылар.



**11нче гыйнвар - Тыюлыклар көне**

Бу көн беренче тапкыр 1997 елда Кыргый табигатьне саклау үзәге инициативасы буенча үткәрелә. 1916 елның 11 гыйнварында төзелгән Баргузинский дәүләт тыюлыгы сәбәпче була аңа. Максаты - Байкал буенда яшәүче кеш һәм бүтән төрле җәнлекләрне саклап калу һәм аларның санын арттыру.

Хәзерге вакытта Россиядә 100дән артык тыюлык бар һәм аларның гомуми мәйданы 33 миллион гектардан артып китә. Бу - илнең гомуми территориясенең 1,58 проценты дигән сүз. Моннан тыш, 35 милли парк бар һәм аның мәйданы 7 миллион гектарга (ил территориясенең 0,41 процентпроценты) җитә. Үсемлек һәм җәнлек дөньясының 80 процент төрен саклыйлар.

Бу көн аерым саклана торган территориядә эшләүчеләрнең һөнәри бәйрәме булып санала. 2013 ел исә аерым әһәмияткә ия, чөнки Татарстан Республикасы Президенты Р.Миңнеханов боерыгы буенча агымдагы ел

***Хөрмәтле укытучыларыбыз!***

***Абдуллина Динә Альбертовна (09.02)***

***Батыршина Миләүшә Рубисовна (09.02)***

***Гордеева Дарья Вячеславовна (15.02)***

***Воронина Юлия Алексадровна (21.02)***

***Нәҗмиева Диләрә Илдаровна (23.02)***

***Сезне туган конегез белән ихлас котлый-
быз! .Бәхетле, озын гомер һәм
сәламәтлек телибез!***



**Редакциянең адресы**:420101, Казан шәһәре, Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576  Тираж – 50 экз.
**Баш мөхәррир һәм дизайнер**:
Габдуллаҗанова А.Ф.

**Редколлегия әгъзалары**:
Соколова София, Овезова Ләйлә, Сафина Камилла, Дзеба Карина